| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ БОЕРЫК

23.06.2023 ел Баулы шәһәре №77

Баулы муниципаль районы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар Исемлеген раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы “Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Федераль законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеген кушымтага ярашлы рәвештә расларга.

2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге җитәкчесен хайваннарны хуҗаларсыз элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

“Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю. Соколов

2023 елның 23 июнендәге
77 номерлы Баулы
муниципаль районы
“Баулы шәһәре” муниципаль
берәмлеге карары белән
РАСЛАНГАН

Баулы муниципаль районы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗаларсыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеге

1. Балалар уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.

2. Җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, күпләп ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).

3. Мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.

4. Мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.

5. Җәмәгать туклануы оешмаларына, сәүдә объектларына, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннарына якын территорияләр.

6. Йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннар.

7. Күп фатирлы йортларга якын территорияләр, аларда мондый йортларга хезмәт күрсәтү һәм эксплуатацияләү өчен билгеләнгән объектлар һәм бу

территорияләрне төзекләндерү элементлары, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары), тротуарлар һәм автомобиль юллары, шулай ук күп фатирлы йортларга якын территорияләргә юллар барлыкка китерүче автомобиль юллары.

8. Зиратлар һәм мемориаль зоналар.